**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫНЫҢ IV ЧАКЫРЫЛЫШ XXV СЕССИЯСЕ**

**КАРАР № 144**

Мөслим авылы «05» май 2023 ел

**2023 елда Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. 2023 елда яллаучы (эш бирүче) вәкиле карары буенча җирле үзидарә органнарында һәм Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының муниципаль органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрелмәскә мөмкин дип билгеләргә.
2. Әлеге карарның 1 пункты Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына билгеләнгәндә кулланылмый.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында (https://muslumovo.tatarstan.ru/) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
4. Карар рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Мөслим муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе Гарипов Р.Г. ка йөкләргә.

Мөслим муниципаль районы Башлыгы,
Мөслим муниципаль районы Советы рәисе А.Р.Хуҗин